**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.01.2025 № 88

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "Нурлат муниципаль районында социаль ипотека программасы буенча торак урыннары сатып алуга кичекмәстән ярдәмгә мохтаҗ гражданнарны тану тәртибен һәм шартларын раслау турында" 2016 елның 27 июлендәге 669 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында, "Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында" 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча алга таба чаралар турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 02 августындагы 366 номерлы карары нигезендә, республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү, торак шартларын яхшырту, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 18 маендагы 559 номерлы Указының 4 пунктындагы 2 абзацы, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 31 пункты, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 31 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 27 июлендәге 669 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районында социаль ипотека программасы буенча торак урыннары сатып алуда кичекмәстән ярдәмгә мохтаҗ гражданнарны тану тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 3.1.11 пунктның 3 абзацын төшереп калдырырга;
– 3.1.3 пунктының 2 абзацын төшереп калдырырга;
– 3.1.4 - 3.1.6, 3.1.8, 3.1.11 пунктларын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында (nurlat.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин